# ЙӨЗ ЕЛ ЭЛЕК

## I

1810 нчы елның 30 нчы май көне иде. Кояш түбәнәеп, көн кичегеп бара; язгы һаваның ләтафәте[1] өстенә кичкә каршы була торган аз гына салкынлык кушылып, бертөрле рәхәт вә шатлык хис кыйлдырмакта иде. Һәр нәрсәдә бер талгынлык вә һәр йирдә бер сөкүнәткә мәел[2] башланган; шау-шулы no мәшәкатьле көнне үткәреп, тын төнгә якынаю әсәре бөтен тирә-якны каплаган иде. Шул вакыт Уфа губернасы, Эстәрлетамак өязенең Югары күл атлы бер авылына яхшы тарантаска өч ат җиккән, кыңгырау таккан бер түрә килеп төште.

Бу түрә — озын буйлы, калынрак гәүдәле, ак сакаллы, мәһабәт вә кибари[3] кыяфәтле бер адәм булып, янында кятиб[4] вә тәрҗеманлык[5] вазифасын үти торган бер татар мирзасы һәм дә ат тотып утырган, зур сакаллы вә ачулы йөзле бер рус бар иде. Ул, авылга керү белән, мәхәллә имамының йортын сорады да, атларны шул мулланың йортына туктатып, авыл халкын җыярга әмер кылды. Бу көн сабан туе булу мөнәсәбәте илә халыкның һәммәсе өйдә иде.

— Түрә чакыра... Тизлектә хәзрәт өенә барыңыз! — дип кычкырып йөрүченең тавышын ишетү белән, өер-өер халык мулланың йортына агыла башладылар. Тиз арада хәзрәтнең өй тирәсен кырмыска кебек халык сырып алды. Умарта корты кебек гөжелдәп вә диңгез кебек дулкынлап тора торган «кеше дәрьясы» хасил булды. Монда килгән халыкның йөзендә гомумән бер курку вә шомлану әсәре чыккан иде. Бу, сәбәбе мәҗһүл[6] булган чакырылудан вә бу көтелмәгән кунактан һәммәсе дә каушаганнар вә, монардан күңелсез бер нәтиҗә тууын сизенгән кебек, борчуга төшкәннәр иде.

Мәхәллә имамы Садыйк мулла исә һәммә кешедән артык курыккан: бу түрә башка берничә мулланың арт сабагын укыткан булганга, иттифакый уларак[7], күптән түгел бер чукынчык татарга кабат исламга кайту хакында юл күрсәткәнгә, шул мәсьәләне тикшерү өчен килмәдеме икән дип, йөрәге тәмам урыныннан кузгалган вә йөзе агарган иде.

Халыкның куркуы тагы башка сәбәптән иде: тегерменче русның өченче көн көтү белән ияреп килгән бер дуңгызыны әллә нинди бер хис белән кыйнарга тотынып, ниһаять, аны имгәткәннәр иде. Дөнья күргән картлар закон кашында дуңгызның бер кылы өчен егерме биш сум түләтәләр имеш,

---

[1]*Ләтафәте* — матурлыгы, нәфислеге.
[2]*Сөкүнәткә мәел* — тынлык теләү.
[3]*Кибари* — горур.
[4]*Кятиб* — язучы, секретарь.
[5]*Тәрҗеманлык* — тәрҗемәчелек.
[6]*Мәҗһүл* — билгесез.
[7]*Иттифакый* уларак— очраклы рәвештә.

аның җәзасы бик каты имеш, дип сөйләдекләреннән, халык түрәнең килүен шул мәсьәләгә хәмел кылмышлар[1] вә шул яктан бер афәт чыгуыннан хәвеф итмешләр иде.

Ләкин халык та, мулла да яңлышты. Түрәнең килүе бөтенләй башка сәбәптән иде: моннан ун көннәр элек ат көтүчесе Салих картның яшь хатыны Камилә белән «урыс Пәкри» (Әбубәкердән мөхәффәф[2]) дигән бер егетне уйнаш кылуда (хилафе шәргъ[3] мөнәсәбәттә булу) төһмәт итеп[4], халык вә мулла бергә бик яхшы гына тукмаганнар, өстәвенә екетнең чәчен үтмәс пәке белән кырып азаплаганнар иде. Мөттәһәм[5] екет бу җәзаны күтәрә алмады.

— Мине нахак җәзаладылар; эшнең асылы тикшерелсен иде, — дип шикаять бирде. Түрә исә шул мәсьәләне тикшерү өчен йибәрелгән иде. Сорау иң әүвәл хәзрәттән булды.

Ул русча белми, үзе бик каушаган иде. Түрәнең сөален әтрафлы[6] аңлап бетмичә үк җавапка керешеп, керделе-чыктылы сүзләр сөйләде. Сүзенең хөласасы[7]: «Без аны кыйнамадык, тимәдек; фәкать шәригать боерыгынча чәчен кырдырып, тәүбә генә кылдырдык», — диюдән гыйбарәт иде. Татар мирзасы моны русчага тәрҗемә итеп биргәч, түрә бер сүз димәде, сөальне дәвам иттермәде; фәкать «алдаганы йөзеннән, сүзеннән билгеле» дигән уй белән башын гына селекте.

Соңра картлардан вә халыктан, берәм-берәм кертеп, сорый башлады. Болар «тәфтиш-фәлән булса, фәлән рәвешчә җавап бирербез» дип сүз беркетеп куймаганга, җаваплары мантыйксыз һәм дә бер-беренекенә мохалиф[8] чыкты. Үзен котылдырасы килгәннәре: «Мин ул җыенда булмадым», — диде. Кайберәүләре каушап, ни дигәнен белмичә: «Безнең шәригать шулай куша бит!» — дип ычкындырды. Бәгъзе бер гаюрлары[9], кызып-кызып: «Син безнең шәригать кушканны эшләүдән тыясыңмы... денгә тияргә уйлыйсыңмы?.. Уйнаш итмәсәләр, кыйнамас идек...» — дип салдылар.

Соңра шул гөнаһның сөбүтенә[10] гуаһлык биргән[11] адәмнәрдән сорарга тотынды. Алар да русча белмиләр; аларның да сөйләгәнен татар мирзасы тәрҗемә кыла бара иде. Боларда да курку юк түгел иде. Шөйлә исә дә[12] болар башкалардан батыррак сөйләделәр, җаваплары да бертөрлерәк чыкты.

---

[1]*Хәмел кылмышлар* — юраулар.
[2]*Мөхәффәф* — бозылган, үзгәртелгән.
[3]*Хилафе шәргъ* — шәригатькә каршы килә торган.
[4]*Төһмәт итеп* — яла ягып.
[5]*Мөттәһәм* — яла ягылган кеше.
[6]*Әтрафлы* — тулысынча.
[7]*Хөласасы* — кыскасы.
[8]*Мохалиф* — каршылыклы.
[9]*Гаюрлары* — кызу канлылары, гайрәтлеләре.
[10]*Сөбүтенә* — дөрескә чыгуына.
[11]*Гуаһлык биргән* — шаһит булган.
[12]*Шөйлә исә дә* — шулай булса да.

Инде кояш та баткан, караңгы да төшә башлаган иде. Түрә үзенең төбәп килгән эшен әтрафлы тикшерде, җавапларны яздырып алды да кире юнәлде. Тын вә сакин[1] булган авыл өстеннән кыңгырау тавышы яңгырады,

Халык исә, бер яктан өстләрендәге агыр йөкне төшергән кебек, икенче яктан, шул тәфтиштән бер тәмсез нәтиҗә чыгар кебек, мохтәлиф[2] хисләр берлән өйләренә таралдылар.

## II

Бүген дә Уфадан туксан чакрым ераклыкта Карлыман башы дигән бер авыл[1+] бар. Хәзер биш олуг мәсҗетле, базарлы, мәктәп вә школалы вә ярыйсы ук мәгъмүр[3] булган бу авыл моннан бер гасыр элек (югарыдагы вакыйга булган 1810 нчы елларда) илле-алтмыш йорттан гыйбарәт кечкенә вә ярым мәдәни булган бер карьячектән[4] гыйбарәт иде. Ул вакыт моның исеме дә Карлыман башы түгел, бәлки Югары күл иде. Бер гасырдан гыйбарәт заман моның һәр нәрсәсен үзгәртте: исемене дә, җисемене дә; шу дәрәҗә ки, аның хәзерге хәле белән ул вакыттагы хәлен чагыштырып караганда, бик зур аерма хис кылынадыр.

Исеменнән дә аңлашылдыгы үзәренә[5], бу — мөселман авылы булып, торучылары фәкать мөселманнар гына, рустан вә башка халыктан һичкем юк иде. Халык авылга кяфер кертергә гомумән каршы торалар иде[*]. Шул иске заманда бөтен авылга бер данә дә кибет булмавын мөлахәзә итеп[6], бер рус авыл халкыннан шунда кибет ачарга рөхсәт сораса да, рәд җавабы[7] алмыш: «Арага кяфер керсә, гөнаһ шомлыгы тияр, афәт вә кыйхтлык[8] килер» — дип, бары беравыздан рус керүенә каршы тормышлар иде. Хәзерге көндә бу авыл, яңа мәдәниятнең төрле ягы белән файдаланып, киңрәк бер кала рәвешенә кереп бара исә дә, ул вакыт бик аз мәдәниятле вә бик садә вә бик тәкәллефсез[9] иде. Халкы даими кәсеп, көч вә һөнәр белән түгел, бәлки табигый байлыкка бик аз хезмәт кушып кына яшиләр; тормышларының һәр ягында табигыйлеккә вә табигатькә якын, зиннәт вә тәкәллефаттан ерак торалар; ачлык күрмиләр; эшләп тә ватылмыйлар иде. Табигать аларның тирә-ягын үзенең кыйммәтле хәзинәләре белән каплаган: бу көн биш-алты зур авыл кулында булган йир-суны ул вакыт алар бер үзләре билиләр иде.

---

[1]*Сакин* — хәрәкәтсез.
[2]*Мохтәлиф* — каршылыклы.
[3]*Мәгъмүр* — төзек.
[4]*Карьячектән* — кечкенә авылдан.
[5]*Аңлашылдыгы үзәренә* — аңлашылганча.
[*]1957 елда чыккан “Сайланма әсәрләр”ендә бу җөмлә төшерелеп калдырылган.
[6]*Мөлахәзә итеп* — күреп алып.
[7]*Рәд җавабы* — кире җавап.
[8]*Афәт вә кыйхтлык* — бәла-каза һәм корылык, ачлык.
[9]*Садә вә тәкәллефсез* — гади һәм ясалусыз.

Һәртөрле зур вә карт агачларга бай булган караңгы урманнар, фәүкылгадә[1] рәвештә мөнбит булган[2] кара туфраклы игенлек йирләр, үләне адәмнең биленә җитә торган печәнлек тугайлар вә чирәмнәр шу кадәр күп вә шу кадәр мул иде ки, Югары күл халкы аның уннан бере беләп дә файдаланып бетә алмый — калганы кул тими ята иде.

Йир-судан болай аз истифадә кылуларына[3] аларның көч вә саннарының азлыгы вә табигый сәрвәтнең[4] артык күплеге сәбәп булган кебек, иген, печән вә башка эш коралларының бик простой вә бик тупас булуының да бу хакта зур тәэсире бар иде.

Эш коралы чынлап ук бик простой вә тупас иде. Бу көн бер кеше вә ике ат белән уйнап эшләнә торган тимер сабаннар урынына, алар әллә нинди зур төрәннәргә биш-алты ат җигеп, өчәр кеше мәшәкатьләнеп чак йөртәләр иде. Уру, чабу, сугу вә җилгәрү эшләрендә дә һичбер төрле машина истигъмаль кылынмый[5], кылынмый гына түгел, андый нәрсәнең имкяненә[6] зиһен дә бармый иде.

Шунлыктан, гөрләп вә яшәреп утыра торган чирәмнәр вә мөнбит йирләр әзәлдән[7] бирле сабан керми яталар; олуг-олуг тугайлар чалгы күрмиләр; караңгы урманнар гомергә шаулашып утырып, балта вә пычкылар белән бер дә рәнҗетелмиләр иде.

Табигый сәрвәткә бу кадәр бай булучылык аларның хәятын тәэмин кылганга, бөтен тәрәккыятьнең[8] анасы булган «ихтыяҗ вә зарурат» күрелмәгәнгә, алар тын гына, бер көй генә иске эздән агалар, бертөрле дә кәсеп вә һөнәргә ныгытып кул сузмыйлар иде. Бөтен авылга бер генә данә дә тимерче, тегүче вә буяучы кебек һөнәр әһелләре вә кибетче кебек сәүдәчеләр юк иде. Чөнки ихтыяҗ юк иде.

Бик вә бик сирәк уларак тимерчегә ихтыяҗ төшә калса, калага барганда яки еректагы тимерче руста аны үтиләр; тегүче кирәк була калса, сәйяр[9] Казан тегүчеләренә бирәләр; ләкин буңа да зарурат юк диярлек иде. — Алар һәммә нәрсәләрен үз куллары белән простой рәвештә оештыралар иде.

Базар кашында болар бигрәк тә баш имиләр иде. Алар тормышының кай ягына караганда да, «йорт эше — кул эше...» белән канәгатьләндекләре күренә иде. Сатып алу дигәнгә алар күп якын бармыйлар иде. Алар үзләренең простой вә килешсез өй вә каралтыларын үз урманнарындагы агачтан үзләре

---

[1]*Фәүкылгадә* — гадәттән тыш.
[2]*Мөнбит булган* — уңдырышлы булган.
[3]*Истифадә кылуларына* — файдалануларына.
[4]*Сәрвәтнең* — байлыкның.
[5]*Истигъмаль кылынмый* — кулланылмый.
[6]*Имкяненә* — мөмкинлек булуына.
[7]*Әзәлдән* — борыннан, мәңгелектән.
[8]*Тәрәккыятьнең* — прогрессның.
[9]*Сәйяр* — авылдан авылга йөрүче.

кисеп ташып, үз авылларының балтачыларыннан эшләтәләр; өенең башын тимер белән яптыру, буяу вә башка йирләрен матурлау кебекләрнең һичберенә илтифат итмиләр иде. Өенең эче дә тышы кебек үк простой булып, анда көзге, сәгать, шкаф, лампа, пәрдә, кыйммәтле сандыклар, палас вә саир[1] зиннәтләрдән бере дә булмый — боларны сатып алып мәшәкать чигелми иде. Кич белән эш эшләргә тугры килсә, алар безнең кебек лампа, шәм вә электрик шикелле нәрсәләр яндырып маташмыйлар, бәлки үз урманнарыннан китергән каен агачын ярып киптерәләр, чыра ясыйлар да шуны яндырып, яктысында эш эшлиләр иде. Шунлыктан лампа, шәмдәл, шәм вә саир ягу әсбабыннан беренә дә ихтыяҗлары төшми иде. Аларның бар азыгы иген белән малның тугрыдан-тугры биргән нәрсәләреннән гыйбарәт булып, тәкәллефле[2] ашларны вә хосусән чәй эчүне белмәдекләреннән, самовар, чәйнек, чынаяк вә саир чәй кирәкләре алып мәшәкатьләнмиләр иде. Ашау-эчүдә булган кебек, кием-салымда да алар Мәскәүнең эшләп чыгарганын көтеп тормыйлар, аңа кирәксенмиләр, бәлки йорт нәрсәсе белән иктифа кылалар[3] иде. Аларның ире, хатыны, бае, ярлысы гомумән үзләре чәчеп үстергән пәҗи[4] вә җитеннәрдән үз куллары илә эшләнгән киндер вә алачадан күлмәк кияләр; тун, чикмән, шарф, бияләй вә оекларның һәрберсен дә үзләренең сарыкларының җон вә тиресеннән үзләре хәзерлиләр иде. Йорт эшендә тәгассыб[5] дәрәҗәсенә барып, тунның төймәләренә кадәр тиредән үзләре ясап куялар иде.

Бу садә тормыш фәкать бу авылда гына булмыйча, бөтен тирә-якта гайн[6] шул хәл хөкем сөргәнгә, төрле үзгәрүләргә вә чит якларга чыгып йөрергә иҗбар итәрлек[7] эшләр булмаганга, алар күптән шулай яшәп киләләр, сату-алу, кәсеп вә һөнәргә кул сузмыйлар иде, чөнки мәҗбүрият юк иде. Базарга аннан нәрсә сатып алу җәһәтеннән мөнәсәбәтләре зәгыйфь булган кебек, аңа китереп нәрсә сату да вә гомумән сатучылык тугрысында да аларның эше ноль (сыйфр[8]) дәрәҗәсендә иде. Үзләре сатып алмаган кебек, кулларындагыны сатып та рәхәтләнә алмыйлар иде, шу кадәр урманнан, хисапсыз печәнлекләрдән вә игенлек йирләрдән һичберен сату юк иде. Чөнки алучы юк; тирә-як бар да йир-суга үзе бай иде. Үскән игенне сату гадәте булгаласа да, аның хакы хәзергенең унбишеңнән бере дәрәҗәсендә генә булганга, начар вә төзәтелмәгән юлдан алама збруй белән ерак калага барып

[1]*Саир* — башка.
[2]*Тәкәллефле* — талымлы.
[3]*Иктифа кылалар* — канәгатьләнәләр.
[4]*Пәҗи* — киндер.
[5]*Тәгассыб* — фанатизм.
[6]*Гайн* — нәкъ.
[7]*Иҗбар итәрлек* — мәҗбүр итәрлек.
[8]*Сыйфр* — ноль, юк.

сатып йөрү мәшәкатен күтәрерлек булмый иде. Шунлыктан бу мөхитнең сату-алу дәрәҗәсе сыйфрга якын иде.

Бу халык мәгънәви яктан бик аз мәдәни иде. Алар эчендә бөтен эштә тупаслык хөкем сөрә; уку-язу белүчеләр һәр авылда имамга башка йә була, йә юк иде. Хәзерге кебек һәр авылда мәктәп, әллә ничә мәсҗетләр булу кайда, болар әллә ничә авылга бер генә булалар иде.

Хикәянең зәмине[1] булган Югары күл авылында борыннан бирле бер голәма нәселе булып, шулар кулында унҗиденче гасыр буенча бөтен тирә-якка гыйлем тараткан вә муллалар җитештергән бер мәдрәсә дәвам итмеш иде. Фәкать тирә-якның бәхетсезлегенә каршы, унсигезенче гасыр башында бунның мөдәррисе, атаклы Хатип хәзрәт вафат булды. Аның бердәнбер угылы Садыйк әфәнде мәхдүмлек хөрмәте өчен имамлыкка куелса да, мәдрәсәне дәвам иттерерлек икътидары[2] юк иде. Шулай итеп, гасырларча тирә-якны яктырткан бердәнбер мәдрәсә мөнкариз булды[3]. Шәкерт таралды. Садыйк мулла, озакзаман дәвам иткән бер мәдрәсәне таратырлык дәрәҗәдә гыйлем бабында җәяүле булса да, башка тугрыда сәләтле генә булганга, аның өстенә мәхдүмлек хакы да игътибарга алынганга, тирә-як муллаларының алдагысы санала; аның тәхте тәсаррыфында[4] байтак авыллар булып, елның күп вакытын кул астындагы халыкның шикаять вә низагларын[5] карап йөреп уздыра иде.

Байлыгы шәп булганга, дуст-ише күп, түрәләр тирәсендә дә кадерсез түгел иде. Байтак гөнаһларда гафуга да мөзаһһар[6] булгалый иде. Мәнсабка[7] утырганының тугызынчы елы иде ки, ул беренче мәртәбә уларак, көтелмәгән рәвештә хөкүмәт каршысына җавапка алынды.

**III**

Караңгы төшә башлаган иде. Садыйк мулла, үзенең көндәге гадәте буенча, урамда, канау буенда гавам белән бергә байтак гәп вә әңгәмә саткан соң, башланган бер эшне бетерү тиешлеге исенә төшеп, ашыга-ашыга өенә керде. Ул кергәндә өйдә ут ягылмаган — караңгы иде.

— Минем бетерәсе эшем бар; ут яндырыңыз! — диде. Хатыннары шуның хәстәрен күрергә керештеләр. Өлкән хатыны (аның ике хатыны бар иде), сәке астыннан алып, бер аршын[2+] биеклегендә булган бер нәрсәне идән уртасына китереп куйды. Бу — егылмасын өчен төбе агач бүкәненә утыртылган вә югары караган башы чыра кыстырырлык итеп икегә аерылган,

---

[1]*Зәмине* — нигезе, җирлеге.
[2]*Икътидары* — көче.
[3]*Мөнкариз булды* — юкка чыкты, бетте.
[4]*Тәхте тәсаррыфында* — карамагында.
[5]*Шикаять вә низагларын* — зар һәм талашларын.
[6]*Мөзаһһар* — лаеклы.
[7]*Мәнсабка* — хезмәт урынында.

бер вершок[3+] калынлыгындагы тимердән гыйбарәт иде. Аларның лампасы, шәме, электриге урынына шул истигъмаль кылына иде. Яшь хатын әүвәлдән хәзерләп куйган бер кочак чыраны шул «кыстыргыч» янына китереп куйды да, рәттән өч чыра кыстырып, ут кабызды, чыраның янган күмере һәм көле идәнгә төшмәсен өчен, шул тугрыга бер сулы савыт куйды. Соңра өй эчендә булганнар берәм-берәм ут янына җыела башладылар. Иң түргә битләре җыерчыкланып, биле бөкрәеп беткән, башына өрпәк[4+] сарган бик карт бер карчык килеп утырды. Бу — Садыйкның анасы иде.

Яшь вакытында язу белмәгән исә дә, Хатип әфәндегә хатынлыкка килгәч, уку-язу өйрәнгән бик суфия вә мөттәкыя[1], шуның илә бәрабәр авылда бердәнбер язу таный алучы хатын иде. Ут янына утыргач: «...йа Алла... сөбханалла... әстәгъфирулла», — дип берничә мәртәбә уһлады да кулындагы язма китабын ачып, укый башлады. Бу — бер догалык һәм вирд[2] иде. Аның түбән ягына өстенә керле киндер күлмәк кигән, башына садә кызыл яулык ябынган сары йөзле, урта буйлы бер хатын утырып, тегенә башлады. Бу — мулланың карт хатыны булып, кулындагы эше — ялчыларга чикмән иде. Утның икенче ягына шул ук төстә киндер күлмәк кигән, кызыл яулык бәйләгән бер хатын утырып, оек ямый башлады. Бу — яшь хатыны иде. Аның түбән ягына бер яшь кыз утырды. Моның йөзе чибәр, әгъзалары килешле генә булып, өстендәге күлмәге башкаларныкы кебек кул эше булса да, алача түгел, бәлки матур төсле киҗеле һәм төрлечә чобарлаган да иде. Моның яулыгы да, артындагы чулпысы да бер төрле зиннәт бирәләр иде. Бу — мулланың кызы булып, кулындагысы — булачак киявенә бирнә иде.

Садыйк мулла өстендәге тунын салды да (ул җәй булса да, кичке намазга тун киеп бара иде) шүрлектән бер каурый каләм, үзе ясаган кара һәм дә бик калын тышлы зур китап алып, анасы янына киезгә таянып, язарга хәзерләнде. Аның күзләре үткен түгел иде. Сиксән яшьлек анасы хәреф аера алган яктыда ул яза алмады.

— Мин болай гына яза алмыйм; тагы ике-өчне куеңыз! — диде. Ике чыра куйдылар. Әүвәлдә өчәү куелган иде. Мәҗмугы биш чыра булып, алар өйне тәмам яктырттылар. Аның һәр йире ачык күренде. Күзне өйнең кайсы ягына юнәлдергәндә дә, төтен белән яхшук каралган коры стена белән ишек төбенә чөйгә эленгән тун вә чикмәннәрдән башка бер нәрсә дә күренми иде. Садыйк, җитәрлек якты хасил булгач, бисмилласын укып, язарга тотынды.

**IV**

Аның, язмак булып, кулына алып утырган нәрсәсе — Коръән иде. Бу

---

[1]*Суфия вә мөттәкыя* — гыйбадәт белән шөгыльләнүче һәм динче, тәкъва.
[2]*Вирд* — догалар, аятьләр.

Коръән, аның һәм башкаларның кашында сәмави[1] булуга башка, берничә төрле хасиятләргә, шәрәф вә кодсиятләргә[2] малик булып, бәнагаһ[3] шуңа бер каза ирешкән; Садыйк исә шуны төзәтергә тотынган иде. Ул хәл шуннан гыйбарәт иде: ул вакытлар басма китап булмаганга, һәрнәрсә кулъязмада йөртелә, китаплар гаять кыйммәт була иде. Дөрест вә ачык язылган Коръәннәр хосусән инабәтле[4] адәмнәр тарафыннан язылса, бер яхшы ат бәһасыннан да арзанга табып булмый иде. Садыйк мулладагы Коръән исә, бик могтәбәр бер хәттат[5] тарафыннан язылып, бабасы заманында бик кыйммәтле бер айгыр биреп алынган; аның өстенә атасы Хатип хәзрәт тарафыннан кат-кат икмаль вә истигъмаль ителгән[6] иде. Шунлыктан аңарда һәркем бер тәбәррәк[7] вә бер кодсият[8] күрә: ул тирә-якта «хәзрәт Коръәне» дип мәшһүр булып, һәр авыруга шифа дип ышаныла; катыргылары җуылып эчелә: хосусән җенләнү кебек авыруларны дәфгыйдә[9] бу Коръән иң баш мөәссир[10] санала иде.

Якын арада күрше авылның бер егете җенләнеп, шуның җеннәрен качыру өчен «хәзрәт Коръәнен» алып киткән булганнар; гөнаһ шомлыкка каршы, авыру, ничектер форсат тапкан да, күкрәгендәге Коръәнне ыргытып бәреп, берничә сәхифәсен өзгәләп өлгергән. Менә шул казаны Садыйк мулла, берничә көннән бирле, рәнҗи-рәнҗи төзәтмәктә улып, инде бу көн тәмам итмәк нияте илә утырган иде.

Ул язуга тәмам бирелеп кенә беткән иде, тыштан бер кеше, ишек дөбердәтеп: «Хәзрәт өйдә микән?» — дип кычкырды. Садыйк мулла кызу канлы бер адәм булып, ихласы белән эш башлаганда бүлдерүче булса, бик ачуы килә, каны кайный башлый иде.

Тыштан мужикның тупас тавышын ишеткәч, кызып «итеп: «Ни бар, кайсысы тончыккан тагы!!» — диде. Яшь хатын белән кыз теге якка чыктылар. Килүчегә әмер булды. Керде.

Бу — башына белен кебек җәелгән кәләпүш, өстенә ак чикмән, яланаягына башмак-чабата кигән, кызыл битле, урта яшьле, томанлы чырайлы бер адәм иде. Сәлам бирде дә бугазының иң төбеннән чыккан

---

[1]*Сәмави* — күктән иңгән.
[2]*Шәрәф вә кодсиятләргә* — затлылык һәм изгелекләргә.
[3]*Бәнагаһ* — кинәттән.
[4]*Инабәтле* — ышанычлы.
[5]*Хәттат* — каллиграф, матур язучы.
[6]*Икъмаль вә истигъмаль ителгән* – камилләштерелгән һәм файдаланылган.
[7]*Тәбәррәк* — бөеклек.
[8]*Кодсият* – изгелек.
[9]*Дәфгыйдә* — кууда.
[10]*Мөәссир* — тәэсир итүче.

тавышы илә:

— Хәзрәт, сине чакыралар! — диде.

Мулла каушап һәм ашыгып:

— Кем чакыра?.. Нигә чакыра?.. Кайда чакыра?..

— Капка төбеңездә!

Хәзрәт бераз сискәнеп китте. Төндә вә сәбәбе мәҗһүл булган бу чакырышта үзенә бер күңелсезлек чыгар төсле тоелды. Ул кичә каладан кайтканда, бер таныш русына кереп, гадәтенчә бик аз гына кәефләнеп чыккан иде. Теге адәмнең вакытсыз чакыруы сәбәпле шул кичәге эше кылт итеп исенә килде; әллә, мәлгуньнәр, шуны сизделәр микән? — дип курка калды. Ләкин чыкмый хәл юк иде. Өстенә тунын киде дә капкага чыкты. Анда унбишләп адәм тора иде. Иң әүвәлге нәзарда бу адәмнәр һәммәсе йозрыкларын төенләп, хәзрәт өстенә һөҗүм итәргә торган кебек тоелуы аның котын очырса да, бу курку урынсыз булды: халык мулланы хөкем итәргә түгел, бәлки гөнаһ кылган бәндәләрне мулладан җәза кылдырырга килмешләр иде.

Бер егет белән бер хатынны уйнаш итүдә гаепләп, үзләре байтак кына тукмаган соң, шәригать буенча хөкем кылдыру өчен, имам әфәндегә мөрәҗәгать итүне мәгъкуль күрмешләр икән. Буны ишетү белән хәзрәт аптырап калды, ни дияргә дә белмәде.

— Ай, ахмаклар... ай, ахмаклар... Кылган эшләрен кара син... йир йотар бит... йир йотар бит... — дип шелтәләргә вә бу эшнең кабахәтен бәянга тотынды. Көн кич, дөнья бик караңгы, бөтен халык йокыда иде. Мондый олуг мәсьәләне төне белә генә хәл кылырга имкян тапмады.

— Инде хәзер төн булган; хөкем иртәгә калсын. Бүген икесен ике мунчага ябып, каравыллап кунсыннар! — дип, халыкны кайтарды. Үзе өйгә кереп, Корьәнен яза башлады.

**V**

Хилафе шәргъ эш белән мөттәһәм булып, хөкем астына алынган егет — «урыс Пәкри», асылда бу авылныкы булса да, торышы моңда түгел иде. Аның атасы әллә ни бер сәбәп белән урыста байда торганга, Кәрим шунда туып, шунда үскән вә бу көнгәчә һаман шунда бер рус баенда хезмәттә тора иде. Бу авылга һәр елда бер-ике генә мәртәбә кунакка кайта, бу вакыйга исә шул кунак чагында очраган иде. Аның өст-башы, чәч, мыегы вә гадәте тәмаман русныкы төсле булып, бу хәл күп кешеләр тарафыннан аның чын мөселман булуында шик кылынырга сәбәп булмакта, хәтта кайбер вакыт «чукынган имеш» хәбәрләре дә чыкмакта исә дә, ул, вакыйгдә[1], чын ихласлы

[1]*Вакыйгдә* — чынлыкта.

бер мөэмин иде. *Дөрест, аның дингә гамәли вә нәзари[1] мөнәсәбәте бик зәгыйфь булып, ул дини мәгълүматны сайрап бирә алмый; шулай ук гамәл вә гыйбадәттә дә мәдәвамәт кыла[2] алмый иде. Ләкин ул каны, хиссияте вә рухы илә бөтенләй иманлы иде. Ул, тыштан рус кебек йөрсә дә, күңеле бунардан риза булмый, үзенчә, бу эшне гөнаһ дип белә иде. Мөселманнарга гомумән үзендә бер якынлык вә бер кардәшлек хис итә вә аларны үз кешесе кебек карый иде. Хәтта чалма-чапан кигән мәһабәт мөэминнәрне вә олуг манаралы мәсҗетләрне күргән чакта, бәгъзан[3] аның күңеле бөтенләй йомшарып, еглыйсылары килә башлый иде. Шул хис аны эчендә яшәгән рус тормышын сөйкемсез күрсәтә, анардан котыласы вә мөселман агай-эне арасына кайтып торасын китерә иде*. Ул инде күптән үк буңа карар да биреп, фәкать төрле манигълар[4] сәбәпле генә бунысын вөҗүдкә чыгарырга муаффәкъ була алмый[5] килгән иде. Бу ел кайтуында исә, агай-эне илә киңәш итеп, бәлки бөтенләй үк калырмын — кабат руска торырга бармам дигән өмите дә бар иде. Шуның өчен ул озаграк та торган иде.

Пәкри белән юлыгуда гаепләнгән хатын исә ул кунакка кайткан өйнең күршесендә тора иде. Аның ире Салих карт белән якын булганга, Пәкри аларга кереп йөри иде.

**VI**

Икенче көнне иртә сәгать тугыз-ун чамаларында гөнаһлыларга хөкем өчен мәсҗет тирәсенә авыл халкы җыела башлады.

— Пәкри берлән Камиләне тотканнар! — хәбәре таң җиле белән бөтен авылны йөреп чыгып, халык, хосусән хатыннар, мәсьәләне әтрафлы мөхакәмәгә[6] керешкән, бу көн иртәнге сыер вакытында шуңа башка бернәрсә дә сөйләмәгәннәр иде. Бу, сирәгрәк очрый торган эш булганга, һәркемгә бертөрле тәэсир биргән иде. Картлар, җитди кешеләр бундый ярамаз эш кыйлырга батырлык итүчеләрне башкаларга гыйбрәт булырлык рәвештә җәза бирергә; яшьләр вә балалар исә бунда булачак кызыкны күрергә берәм-берәм җыенга агылалар иде. Күршедә ут чыккан вакытта да, «Аллаһы тәгалә саклар әле!» дип, урыннан кузгалмый, чабатасын тугып утыра биргән Гали карт, бөтен авыл халкы кая басарга белми дулкынлана торган фәүкыльгадә эшләрдә дә кулындагы ката торган җомгагын куеп, урыныннан кузгалмаган

---

*1957 елда чыккан “Сайланма әсәрләр”ендә алдагы 5 җөмлә төшерелеп калдырылган.

[1] *Гамәли вә нәзари* — гамәлдәге һәм караштагы.

[2] *Мәдәвамәт кыла* – дәвамлы, даими рәвештә үти.

[3] *Бәгъзан* — кайвакыт.

*1957 елда чыккан “Сайланма әсәрләр”ендә бу җөмлә кыскартылган: *Шул хис аны мөселман агай-эне арасына кайтып торасын китерә иде.*

[4] *Манигълар* — киртәләр.

[5] *Вөҗүдкә чыгарырга муаффәкъ була алмый* — тормышка ашыруга ирешә алмый.

[6] *Әтрафлы мөхакәмәгә* — төрле яклап тикшерүгә.

Сәлимә әби вә шулар кебек бервакытта андый-мондый эшләргә исе китми торган картлар да бу көн аякка басканнар, шул яманлыкка кул сузучыларга хөкем йиренә килгәннәр иде.

Ирләр һәммәсе җыенның үзенә җыелалар, хатыннар исә, ирләр арасына керү мөмкин булмаганга, шунда якын йортларга тулып, читән ярыгыннан карамакталар иде. Һәр эштә үзенең бер тәэсирен күрсәтәсе килгән Вәли бабай күршедәге бер байдан простой вә буяусыз өстәл чыгартып, мәсҗет ихатасы янына куйдырды. Мондый җыеннарда урындык чыгару гадәте булмаганга һәм урындыклар авылда бик сирәк булганга, хәзрәт вә могтәбәранга[1] утыру өчен, мәсҗет ишеге төбендә аунап яткан калын бүрәнәләрне тәгәрәтеп китереп, өстәл тирәсенә утырырга уңгайлап куйдылар. Бераздан соң, башына зур чалма, өстенә иске чапан кигән вә кулына яшел таяк тоткан хәлдә, бик җитди кыяфәт илә имам әфәнде килде. Ул үзен бик сагышлы вә чыннан мөтәэссиф[2] күрсәтергә тырыша иде.

Акрын гына килеп, халыкка сәлам бирде, исәнләште дә өстәл янына салынган калын бүрәнәгә утырды. Аның янына каюсы тун, каюсы озын җиңле камзул вә күбрәге яланаякка башмак-чабата кигән авылның картлары, бай вә могтәбәр адәмнәре тезелделәр. Халык күп иде. Кечек бер авылдан бу кадәр адәм җыелуы «килми калган һичкем юктыр» фикерен искә төшермәктә иде. Үзләре һәммәсе садә кыяфәттә иде. Бик күпләре керле күлмәк вә яланаяк белән килгәннәр. Арада камзул вә чикмән кигәннәре, башларына каешланган кәләпүш салганнары да бар иде.

Хәзрәт килеп утырган соң, кичә күргән адәмнәрдән мәсьәләнең әтрафын тәмам сорашты да мәгъюбләрне[3] китерергә әмер кылды. Алар, төндә сакланган өйләреннән чыгарылып, мәсҗет янындагы бер йортка куелганнар иде. Хәзрәтнең әмерең ишетү белән, балалар һәм екетләр әллә нәрсә күргән кебек чабышып, шул йортка киттеләр. Берничә минуттан соң өстенә кара чикмән, аягына итек, башына картуз кигән вә чәчләрен русныкы кебек үстергән бер екет халык күз алдында заһир булды.

Бу — мөттәһәм[4] Пәкри иде.

Аның йөзе бик үзгәреп, талгын вә хәятсыз кыяфәткә кергән, борчу вә курку каплаган иде. Үзе яхшук басылган булса кирәк, аякларын чак кына өстерәп атлый иде. Буның килеп чыгуы илә бөтен халыкның күзе шуңа юнәлде. Хосусән балалар шайтан күргәннән артык кыланып, мәгъюбнең тирәсен сырып алганнар, аңа әллә нинди бер җырткыч вә усал хайванга караган кебек карыйлар иде. Пәкри берәүгә дә күтәрелеп карамады, бер сүз

[1]*Могтәбәранга* — ихтирамлы кешеләргә.
[2]*Мөтәэссиф* — кайгылы.
[3]*Мәгъюбләрне* — гаеплеләрне.
[4]*Мөттәһәм* – гаепле дип саналган.

димәде, фәкать хәзрәткә сәлам ишарәсе бирде дә тын гына өстәл янына килеп, йиргә тезләнде. Аның башы астка иелгән, күзләре туфракка караган иде. Халык исә бөтенесе күзләрен Пәкри өстенә кадаганнар иде.

Хәзрәт сорый башлады:

— Энем Әбубәкер, ялганлап, ике гөнаһка батма, дөрестен сөйлә: бу эш синнән булдымы, юкмы? — Хәзрәтнең сөале урынсыз күренде булса кирәк, мәхкүмнең[1] җавабын көтмичә үк, читтән берничә адәм:

— Нигә сорап торырга инде... Без үз күзебез белән күрдек ич...

— Мин бу эшне эшләдем дип ул гомердә әйтмәс, — дип кычкыра башладылар.

Хәзрәт йомшак тавыш илә:

— Чүеңез, җәмәгать, чү! Шәригать мәгъюбнең үзеннән дә сорарга куша! — диде. Баягы сөаль тәкрар ителде.

Мәхкүм үзенең көч вә батырлыгын җуя төшкән иде. Мәзлум[2] вә мескен бер тавыш илә:

— Юк, хәзрәт, биллаһи, валлаһи, юк... Алла сакласын шундый эштән! — дип кайтарды.

— Шаһитләр, бар, ди бит, күрдек, диләр бит!

— Сөяксез тел ни сөйләмәс... Мин аларның өенә йомыш белә генә кергән идем. Сабан туена бару өчен Салих агайның иярен сорамакчы идем...

Халык шаулады. Шәһитләр ачулана, кыза башладылар. Төрле яктан бик чын ачу белән:

— Кара мәлагуньне... кара урыс башын... күзен дә йоммый алдап тора бит... Эт баш... авызын кара кан белән юганны көтәдер... явыз... — кеби сүзләр ишетелә башлады.

Шул арада халык ишерелеп, егетне кыйнарга һөҗүм кылганнар иде, хәзрәт, сикереп торып:

— Сорау тәмам булмый торып, кул сузу ярамый, — дип халыкны тыйды.

Соңра хатынны китерделәр.

Урта буйлы, таза вә ямьле гәүдәле, төскә-биткә чибәр генә, егерме ике яшьләрендә бер хатын иде. Өстендә алача-киндер күлмәк, башында иске җилән иде. Артык күп еглау сәбәпле ифрат куркыныч та, кызганыч та булган бер кыяфәткә кергән бите озаеп, йөзе көлтөсле булган, авызы-борыны салынган, күзе кызарып беткән; шулар өстенә чәченең тузып, йөзенә төшеп торуы дәхи бер авыр күренеш бирә иде.

---

[1]*Мәхкүмнең* — хөкем ителүченең.
[2]*Мәзлум* – рәнҗүле.

Хәзрәтнең һәрбер сөаленә аерым вә мөгайян[1] җаваплар бирә алмады, тик карлыккан вә күз яшенә буялган тавышы илә:

— Юк, хәзрәткәем... йир йотсын, юк, кояштыр, юк... — кеби сүзләрне генә кайтара бирде.

Шаһитләрдән берсе:

— Булмагач, ни өчен соң алай ишегеңезне бикләдеңез, нигә ут сүндердеңез? — дип кычкырган иде, моңа каршы хатын ачы тавыш илә:

— И, Илаһым, бар икән Ходайдан курыкмый алдаган кешеләр, — диде дә елап җибәрде.

Шаһитнең: «Нигә ишек бикләдеңез?» — диюе һәм дә хатынның еглавы Салих картның ирлек гыйззәтенә[2] тукынды булса кирәк: ул ачуына чыдаша алмый, тешләрен кысып, хатын өстенә очынып килде дә:

— Ә син, марҗа ... син, курба... Мин... мин ак сакалым белән... карт көнемдә сезнең өчен ат көтеп йөрим, ә син монда яшь екетләр белән ... мәлагунь... — дип, Камиләне яңаклый һәм типкәли башлады. Аның чамадан тыш кызуын күреп, туктаттылар, юкса ул хатынны изәчәк иде.

Соңра шаһитләрдән соралды.

Алар һәммәсе беравыздан:

— Без берничә көннән бирле сагалап йөри идек, ниһаять, эләктердек...

— Пәкри посып кына керде дә, өйдәге утлар сүнделде.

— Без өсләренә барып... — диделәр. Моңа каршы екет:

— Алдыйлар, хәзрәт, мин үз йомышым белән кергән идем; ут ишек җиле белән сүнде, — дисә дә, төрле яктан җәрех кылдылар[3].

Халыкның гөнаһлыларга мөгамәләсенә караганда, монда җыелучылардан һичкем екетнең гаебе бармы-юкмы идекене тикшереп тормый, гүя анарда гаеп булучылыгы әллә нинди бер дәлил белән катгыян беленгәндә, инде мәсьәлә шул гаепкә җәза бирүдә генә калган төсле караганлыклары күренә иде. Хәзрәт бу мәсьәләдә битараф булып, этрафлы тикшерүне теләсә дә, халыкны җиңә дә алмый һәм гавамның «усалларны яклады!» дигән сүзеннән дә курка иде. Шунлыктан зур куәт белән халык мәеленә[4] каршы бармый иде. Ниһаять, үзләренчә гөнаһның сөбүтенә карар биреп, шуңа тиеш булган җәза хакында шаулый башладылар, карт авызлардан бу хакта төрле сүзләр чыкты; кайберәүләре: «Мөфти хәзрәтенә тапшырыйк!» — диделәр. Ләкин күплек моңа каршы торды:

— Безнең карт мулла, Хатип хәзрәт мәрхүм, мондый эшләрне бер дә мөфтигә-фәләнгә калдырмый иде. Үзе кулындагы калын таягы белән хәле

---

[1]*Мөгайян* — ачык.

[2]*Ирлек гыйззәтенә* — ирлек намусына.

[3]*Җәрех кылдылар* — хурладылар.

[4]*Мәеленә* — теләгенә.

беткәнче кыйный-кыйный иде дә соңра безгә куша иде, без тукмыйдыр идек. Шуның белән эш бетә иде, — дип, эшне үзара бетерүне мәгъкуль күрделәр. Халык шул мадә[1] хакында шау-шу килмәктә, имам әфәнде исә кулындагы «Җәмигыйр-рөмуз»еннән[5+] төрле ихтиляфларны[2] укып, мәсьәләне шуларның беренә татбикъка[3] маташа иде. Шул вакыт мәсҗет күршесендәге өйдән бер хатын йөгереп килде дә үзенең ире аркылы:

— Камилә бүген бездә кунган иде, ул безгә, мин теләмәгән идем, Пәкри мине көчләде, җәбер кылды, дип әйтте, — диде.

Халык капыл җанланып китте. Бәгъзе бер картлар: «Хатыннарга ышанырга ярамый», — дип карасалар да, күпчелек бу сүздән бөтенләй җенләнде.

— Дөрестме, сине көчләдеме? — дип, Камиләнең үзеннән сораганнар иде, ул башта «юк» дип җавап бирсә дә, төрле яктан аны:

— Әйт шулай дип, котылырсың! — дип кыстый башлагач, «әйтергә оялам» дип ычкындырды.

Хатынның авызыннан бу сүз чыгып та бетмәде, аның ире, якыннары вә алар артыннан башка халык та, тилереп:

— Ә син, урыс баш, монда кайтып, безнең хатыннарымызны көчләп йөрисең икән... оятсыз... мәлагунь...авылга кертмәскә кирәк аны, — дип, егеткә берьюлы һөҗүм кылдылар. Яклаучы булмады. Халык исә, үлчәүне тәмам онытып китеп, егетне бик яман кыйнап ташладылар. Хәзрәт һәм бәгъзе бер картлар: «Алай башбаштаклык кылмаңыз, шәригать буенча хөкем итәргә кирәк», — дисәләр дә, халыкның аңа илтифаты булмады, егетнең хәле бетеп, йиргә егылганчы вә авыз-борыныннан кан килгәнче тукмадылар. Егет үзенең фәүкыльгадә тазалыгы аркасында һушыннан язмады исә дә, бик нык изелгән, ватылган иде. Башка берни кылмады, димәде, тик сызланган тавыш илә:

— Уф, Алла... уф, үтерәсез... нахак... нахак... — дип ыңгырашты гына.

Ниһаять, хатын иреннән талак кылынды. Мәгъюбләрнең һәр икесен халык алдында гайре мөгайян[4] рәвештә тәүбә иттерделәр. Соңра Садыйк мулла: «Эш бетте инде!» — дип, урыныннан тора гына башлаган иде, теге һәр тугрыда үзенең бер тәэсирен кертергә сөя торган карт бик зур иһтимам илә[5] сүз башлап:

— Җәмәгать, Пәкри болай мөселманнарны, динне мәсхәрә кылып, әйе, менә безне оялтып йөрмәсен иде, аның чәчен кырырга кирәк, — диде. Сүзен

---

[1]*Мадә* — бу урында чара, хәл мәгънәсендә.
[2]*Ихтиляфларны* — каршылыклы фикерләрне.
[3]*Татбикъка* — килештерүгә.

[4]*Гайре мөгайян* — эшнең асылы ачыкланмаган хәлдә.
[5]*Иһтимам илә* — кайгырткан булып.

бетерү илә, егетнең янына килеп, картузын салдырды да, озын чәченнән тотып селкеп:

— Караңыз моны, бу бит пумала чикле бар... кяфернең... — дип гыйлавә кылды[1].

Пәкринең бер якын кардәше: «Анысын хәзергә куеп торыңыз, өйгә кайткач, мин аны үзем алырым», — дисә дә, халык илтифат итмәде, әүвәлгедән әллә ничә мәртәбә җанланып:

— Калган эшкә кар ява, хәзер кырамыз. Хәзер менә шунда үтмәс пычак белән туныймыз урыс башын! — дип шаулый башладылар.

Шул арада бер хиффәт[2] адәм, кесәсеннән пәке чыгарып:

— Рөхсәтме, хәзрәт? — диде дә, җавапны көтмичүк, егетнең чәчен кырырга тотынды.

Халык тагы тилерде, тагы гөжли башлады. Җыенның күп йирендә шаркылдашып көлүләр, «күптән шулай кирәк иде ул урыс башыны», дип кычкырулар ишетелде. Кесәсендә пәке булган адәмнәрнең һәммәсе, пәкеләрен ачып, «мин кырам да мин кырам» дип тарткалаша башладылар. Халыкның йөзендәге әүвәлге ачу вә караңгылык урынына мәсхәрә көлүе заһир булды[3]. Бунын кызыгы башкалардан бигрәк балаларга артык иде. Алар, үтмәс пәке белән пумала кебек озын чәчнең җүешләмичә кырылганын күрү өчен, кысылып-кысылып, халык эченә вә нәкъ Пәкринең янына керәләр; әләктерә алсалар, егетнең башыннан төшкән бер чирек озынлыгындагы чәчләрне кисәге белән алып китеп, урам буенча:

— Һай-һай... һай-һай... тастымал... — дип куанып чабып йөриләр иде.

Башның яртысы алынган иде. Авылның төньяк башыннан бер кыңгырау тавышы ишетелә башлады. Бу тавыш дәфгатән[4] халыкны үзенә җәлеп итеп, җыендагы бөтен адәмнәрнең колагы торды, күзләре, шыкырдап кырылган баштан алынып, шул тавыш ягына юнәлде. Ни күрсеннәр: ике яхшы ат җигелгән чибәр генә бер кимә авылның эченә, боларга таба кереп килә, якыная. Халык каушады, һәммәсенең йөзендә мәсхәрә көлүе югалып, курку әсәре күренде. Теге гаюр хиффәт адәм дә, үзе сизмичә үк, пәкесен кесәсенә тыкты. Үзара: «Бу кем?.. бу кем?.. түрә түгелме?» — дигән сөальләр йөри башлады. Арадан берсе калтыраган тавыш илә:

— Ах, харап булдык, җәмәгать! Мин атларыннан таныйм: бу — түрә, — дип кычкырды.

Төрле яктан:

---

[1]*Гыйлавә кылды* — өстәп куйды.
[2]*Хиффәт* — җиңел акыллы.
[3]*Заһир булды* — күренде.
[4]*Дәфгатән* — кинәттән.

— Әйе шул... шул... шуңа охшый, — дип тәсдикъ иттеләр[1].

Бу сүзләр әйтелеп тә бетмәде, халык һәммәсе, карчыгадан качкан чәүкәләр кебек, төрлесе төрле якка йөгерә башлады. Хәзрәтнең дә нервылары бик ватылган иде; ни эшләгәнен белмәде — шул халык белән бергә ул да йөгерде.

**VII**

Халыкның бу качуы тиктән-тик түгел, аның бик мөһим сәбәпләре бар иде: өченче ел күрше авылның бер егет басудан арыш көлтәсе урлап тотылган иде. Буңа җәза өчен авыл халкы җыелдылар да егетне арбага җигеп, муенына көлтәләр тактылар; шул хәлдә бөтен урам буена мәсхәрә итеп йөрттеләр. Шул хакта шикаять ителеп, башлап йөргән берничә адәм бик каты эшкә эләгә язганнар иде. Моңа башка, ерактарак Шарлан дигән бер авылда хилафе шәргъ мөнәсәбәттә мөттәһәм булган бер егет белән бер хатынны бөтен халык җыелып кыйнау вә урам буенча мәсхәрә итеп йөртү хакында дәхи зур бер афәт туа язган иде. Түрәгә охшаш бер адәм килеп чыгу белән, монда да халык үзләренә шундый бер афәтнең якынаюын хис кылгандай булдылар. Анардан котылу өчен, үзләренчә, качуга башка чара юк иде. Ләкин бу куркулар, бу качулар урынсыз булды. Кыңгыраулы адәмнәр — түрә түгел, бәлки Эстәрле янындагы бер рус баеның укудан кайтып килә торган унсигез яшьлек кызы илә унбер яшьлек угылы һәм дә аларга ат тотып утырган бер рус карты иде. Болар авылга кергәндә күренгән җыенның аз бер заманда ашыга-ашыга төрле якка качып бетүе аларның бераз тәгаҗҗебен мөҗиб булды[2].

Җыенның янына килгәч, аларның тәгаҗҗебе дәхи артмыш иде. Шул йөгерә-йөгерә качкан халык җыенының урынында калган, бөтенләй рус кыяфәтле булып та, озын чәче яртылай кырылган бер егетне күргәч, болар тәмам аптырап калдылар, ни дияргә дә белмәделәр. Хосусән егетнең авыр күренешле йөзе, кырылган башының кан эчендә булуы кызны бик тирән тәшвишкә салмыш иде. Ул моны кемгә дә хәмел кыла[3] алмады. Күңеленә: татарлар берәр русны көчләп мөселман итеп тә, шуның өчен башын кырганнармы, әллә юкса берәр мәхбүс[4] качып та, татарлар шуны тотып кыйнаганнармы, — аларның башы яртылай алынган була, дигән уйлар килсә дә, очына чыга алмады. Ниһаять, егетнең янынарак атларны бордырып, кучер аркылы мәсьәләнең чынын сорамак булды. Карт, егетнең янына килүе белән:

— Ах, Сәлимов — кем, бу синме? Ни булды?! Ни эшләп бу хәлгә

---

[1] *Тәсдикъ иттеләр* — расладылар.
[2] *Тәгаҗҗебен мөҗиб булды* — гаҗәпләнүен тудырды.
[3] *Хәмел кыла* — юрый.
[4] *Мәхбүс* — тоткын.

төштең? — дип кычкырып йибәрде.

Карт та, аның артыннан кыз да Пәкрине таныдылар. Ул үзенең баена ат тотып, бу кызларга бара, катыша, күп вакыт кызларны көймәдә йөртә вә башкача хезмәтләр дә кыла иде.

Мәсьәләнең бу ягы кызның нәзарын гаять үзгәртте. Ул ни дияргә белмәде... Пәкринең сүзен тыңлап: «Харап бит... харап бит... бу нинди эш?..» — дип башын селкеп, йөзен чытты да торды. Бу эш хакында ярдәмдә булачакларын вәгъдә итеп, бераздан соң кызлар юлларына юнәлделәр. Пәкри исә яртылый кырылган канлы башына рус картузын киде дә ватылган тәнен чак күтәреп өенә китте.

## VIII

Бу мәсьәләнең шул көенчә ятып калуы мөмкин булмады. Имам әфәндене вә мөселман ага-энене мәхкәмәгә[1] тарттырырга Пәкри бик ихлас булмаса да, бае һәм башка руслар димләп, «нахак җәза» өчен Пәкридән шикаятьнамә бирдерделәр. Мәсьәләнең өстенә килеп чыккан кыз белән карт һәм дә яртылый кырылган баш белән җәрәхәтле тәннәр ул шикаятьнең хаклы идекенә шәһадәт бирделәр[2]. Түрәнең шул хакта утызынчы майда килеп, иҗра кылган тәфтише сәясендә[3] эш бөтен әтрафилә яктырып, шикаятьнең бөтен әсасы тәхәккык итте[4].

Вакыты илә бу хәл тирә-якның байтак шау-шуына сәбәп булмыш иде. Буңа аз-маз тәгаллекы[5] булган һәр кеше зур куркуга чумганнар: тиз арада әллә никадәр ясама хәбәрләр чыгып, Садыйк мулла төрмәгә алынган имеш, хәле начар имеш, указы киткән имеш, мәхәллә халкы чыбык белән суктырылачак имеш, кебек сүзләртөрле якларда төрле буяу белән тарала башлаган иде. Эшне әсаслырак аңлаучылар да бу таякның иң көчле зарбәсе[6] Садыйк муллага төшәчәгенә ышанганнар, аның истикъбале[7] хакында төпле рәвештә караңгы вә томанлы хәбәрләр йөри башлаган иде. Ләкин язмыш көләч йөз бирде. Эш ул дәрәҗәгә ирешмәде. Бөтен тирә-якның мөхтәрәме булган олуг хәзрәтнең бердәнбер мәхдүменең мондый кыенлыкка төшү ихтималы Хатип әфәнде мөхибләрен[8] чыннан уйга калдырды.

Ул мөхибләр эчендә байлар да, могтәбәрләр дә бар иде.

Сәрвәт белән игътибарның икесеннән бер куәт ясап, шуның илә

---

[1]*Мәхкәмәгә* — хөкемгә.
[2]*Шәһадәт бирделәр* — шаһит булдылар.
[3]*Иҗра кылган тәфтише сәясендә* — башкарылган тикшерү нигезендә.
[4]*Әсасы тәхәккык итте* — нигезе расланды, дөреслеккә чыкты.
[5]*Тәгаллекы* — бәйләнеше.
[6]*Зарбәсе* — бәреше.
[7]*Истикъбале* — киләчәге.
[8]*Мөхибләрен* — якыннарын.

киләчәк бәлане мөкавәмәт итәргә[1] керештеләр. Килеп җитешкән тәкъдирдә мулланы вә башка беркадәр адәмнәрне изеп яки имгәтеп китүе ихтимал булган афәт дулкыны алтын җиле белән икенче якка борылды: бер якның авызын капладылар. Пәкрине «мин ул эштән ваз кичтем!» дип игълан җибәрергә ризалаттылар.

Шул саядә күкнең казасы бәр тараф булды[2].

---

[1]*Мөкавәмәт итәргә* — каршы торырга.
[2]*Шул саядә күкнең казасы бәр тараф булды* — шуның аркасында күк хөкеме бер читкә тибәрелде.